ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.02.2023 Баулы шәһәре №35

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 142 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 11 декабрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.5. пунктындагы өченче абзацны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.»;

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1. пунктта:

1) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхесне таныклый торган документ (Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклый торган башка документ) яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә мәгълүмат технологияләреннән файдаланып, идентификация һәм аутентификация юлы белән, 14.1 статьяның 18 өлешендә каралган. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон;»;

6) пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

2.6.1. пунктының 12, 17) һәм 18) пунктчаларында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

2.10. пунктының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан күрсәтелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров